| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|
| ГЛАВА СТЕПНООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКҮЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
| 423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная, дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34 | 423009, Бикүле авылы, Мәктәп ур., 23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34 |

ОГРН 1021605352438,ОКПО 04312541, ОКАТО 92246880000,
ИНН/ КПП 1632001635/163201001,ОКТМО 92646480

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 30» ноябрь 2019 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында Мәктәп, Дуслык, Ленин урамнарыннан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2019 елның 11 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка М. Җәлил урамы буенча 23 нче йорт янында Бикүле авылында М. Җәлил урамы буенча 23-51нче, 52-62 нче йортлардан, Гагарин урамыннан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыененың икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 14 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Шоссе урамы буенча 17нче номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Ш. Камал урамы буенча, Шоссейная урамы, Яшел урам буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә.
4. 2019 елның 18 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка М. Җәлил урамы буенча 28нче номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авылының М. Җәлил урамы буенча 2-50 нче номерлы йортларыннан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. 2019 елның 18 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Тыныч урамы буенча 24нче номерлы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында М. Җәлил урамы буенча1-21-нче номерлы, Тыныч, Һ. Такташ урамы буенча, Тукай урамы буенча урнашкан йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының бишенче этабын уздыруны билгеләргә.

6. Бикүле авылында яшәүчеләр исемлеген гражданнар җыенын уздыру өчен сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

7. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла

8. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Бикүле торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау (грунттан юл өслеген күтәрү, вак таш сатып алу, ташу, салу, транспорт хезмәтләре)

2) Бикүле авылын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү

3) Бикүле авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».

9. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

10. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Бикүле авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Садыков